## Су басу –

**ул матди зыян китерә торган, халыкның сәламәтлегенә зыян һәм кешеләрнең һәлак булуына китерә торган, елгага, күлгә һәм сусаклагычка якын булган җирләргә су керүе**



## БЕРДӘМ КОТКАРУ ХЕЗМӘТЕ

# 112



| | | |
|---|---|---|
| ЯНГЫН СҮНДЕРҮ ХЕЗМӘТЕ | 101 | 01 |
| ПОЛИЦИЯ ХЕЗМӘТЕ | 102 | 02 |
| АШЫГЫЧ ЯРДӘМ ХЕЗМӘТЕ | 103 | 03 |
| ГАЗ ХЕЗМӘТЕ | 104 | 04 |

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ һӘМ
ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР БУЕНЧА
УКЫТУ-МЕТОДИК ҮЗӘГЕ

# БЕЛЕШМӘЛЕК

## Су басу вакытында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре




Яшел Үзән шәһәре
2021



**Гадәттән тыш хәл чыкканчыга кадәр башкарасы эшләр:**

- тынычлыкны саклагыз;
- күршеләрне кисәтегез, балаларга, инвалидларга һәм өлкәннәргә ярдәм итегез;
- гадәттән тыш хәл турында хәбәрләр тыңлау өчен радионы кабызыгыз.

**Гадәттән тыш хәл вакытында нәрсә эшләргә:**

**<u>Өйдә чакта:</u>**

- суны ябарга, газ һәм электрны сүндерергә;
- кыйммәтле предмет һәм әйберләрне өске катларга меңгерергә;
- ишек һәм тәрәзәләрне ябарга;
- кирәк булган барлык әйберләрне җыярга: йөзү чаралары, баулар, баскычлар, сигнал бирү җайланмалары;
- йортның түбәсенә, чарлагына яки өске катларына менегез һәм сигнал бирегез:

<u>якты вакытта</u> – ак яки төсле япма белән болгап яки аны элеп куеп,
<u>караңгы вакытта</u> – ут сигналы яки вакыт-вакыт тавыш белән.



**<u>Эвакуация турында кисәтмә алгач:</u>**

- җылы һәм уңайлы кием, аяк киемен, юрганнар, акча һәм кыйммәтле әйберләрне әзерләгез;
- 3 көнлек азык запасы әзерләгез;
- беренче ярдәм даруларын һәм чараларын әзерләгез;
- паспорт һәм башка документларны су үтми торган пакетка төрегез;
- коткару хезмәтеннән эвакуация турында хәбәр алгач, йорттан китегез.

**ҮЗЕГЕЗ БЕЛӘН БИК КИРӘКЛЕ ӘЙБЕРЛӘРНЕ ГЕНӘ АЛЫГЫЗ!!!**



**<u>Машинада чакта:</u>**

- су баскан юллардан бармагыз – агым алып китү куруынычы бар;
- ватык машина белән су баскан урында калсагыз, машинадан чыгыгыз, ярдәм чакырыгыз.



**Гадәттән тыш хәл беткәннән соң башкарасы эшләр:**

- кирәк булганда, зыян күрүчеләргә ярдәм итегез;
- сак булыгыз;
- йорт конструкцияләренең ныклыгын тикшерегез;
- учак яндырмагыз, электр утын кабызмагыз;
- ишек-тәрәзәләрне ачып йортны җиллэтегез;
- газ, электр һәм су белән куллану белгечләр рөхсәтеннән соң гына рөхсәт ителә;
- радио буенча коткару хеәмәте киңәшләрен тыңлагыз.